СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.11.2022 г. Заинск № 103

**«Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәр булмаган белгечләргә һәм эшчеләргә хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 13 апрелендәге 105 номерлы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында»2022 елның 17 сентябрендәге 1013 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының «Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәр булмаган белгечләргә һәм эшчеләргә хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 13 апрелендәге 105 номерлы карары белән расланган (Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының 2020 елның 27 августындагы 194, 2021 елның 27 декабрендәге 79, 2022 елның 29 сентябрендәге 96 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәр булмаган белгечләргә һәм эшчеләргә хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.2 пунктта «11 958 сум» сүзләрен «12 688 сум» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.3 пунктның 3 пунктчасында «ике процент» сүзләрен «15 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләрне кертергә.

3. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре башлыгы урынбасары Е.В.Недошивинага йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**